ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Фән һәм фәнни эшчәнлек турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 25 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Фән һәм фәнни эшчәнлек турында» 1998 елның 18 июнендәге 1661 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 7; 2006, № 5; 2014, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 3 (I өлеш); 2020, № 87 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 2 пунктында «Федераль закондагы» сүзләреннән соң «(алга таба – Федераль закон)» сүзләрен өстәргә;

2) 12 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Фән өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәте түбәндәге принциплардан чыгып гамәлгә ашырыла:

а) фәнне дәүләтнең җитештерү көчләренең үсеш дәрәҗәсен билгели торган социаль әһәмиятле тармак дип тану;

б) фәнни-технологик үсешнең өстенлекле юнәлешләрен сайлаганда һәм конкурслар нигезендә гамәлгә ашырыла торган фәнни, фәнни-техник программаларга һәм проектларга экспертиза ясаганда хәбәрдарлык һәм җәмәгать фикер алышуларының төрле рәвешләреннән файдалану;

в) фундаменталь фәнни тикшеренүләрнең өстенлекле үсешен гарантияләү;

г) югары белем бирү мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең һәм аларда белем алучыларның фәнни тикшеренүләрдә һәм эксперименталь эшләнмәләрдә катнашуының төрле рәвешләре нигезендә югары белем бирү мәгариф оешмаларында лабораторияләр, фәнни оешмалар базасында кафедралар төзү юлы белән фән һәм мәгариф интеграциясе;

д) фән һәм техника өлкәсендә конкуренциягә һәм эшкуарлык эшчәнлегенә ярдәм итү;

е) фәнни-технологик үсешнең өстенлекле юнәлешләрендә ресурсларны туплау;

ж) фәнни, фәнни-техник һәм инновацион эшчәнлекне икътисадый һәм башка ташламалар системасы аша кызыксындыру;

з) фәнни, фәнни-техник һәм инновацион эшчәнлекне дәүләт фәнни үзәкләре системасын һәм башка структураларны төзү юлы белән үстерү;

и) тигез хокуклы һәм үзара файдалы булган нигездә Татарстан Республикасының халыкара фәнни һәм фәнни-техник хезмәттәшлеген үстерү;

к) Федераль закон нигезендә башка принциплар.»;

3) 13 статьяның 3 пунктында «фән һәм техника үсеше» сүзләрен «фәнни-технологик үсеш» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2025 ел, 03 октябрь
№ 62-ТРЗ